Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка М.П. Викторова шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре | 2021 елның 25 мае

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка М.П. Викторова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.С. Мусин мәгълүматын, яклар — гражданка М.П. Викторова, аның вәкиле — А.Э. Кислицына, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче консультанты Р.Җ. Асьмаева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка М.П. Викторова Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 14 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаять белдерелә торган норма нигезендә вәкаләтле банк бүлеге счетыннан торак урын сатучысына яисә торак урынга таләп итү хокукы булган затка акчалар күчерелгәннән соң субсидия файдаланылган дип санала, ә субсидияләр алучылар торак урыннарга мохтаҗлар статусын югалталар.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүченең әнисе — гражданка Е.В. Петрова «Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварындагы 5-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба шулай ук — «Ветераннар турында» Федераль закон) нигезендә һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә

әгъзалары категориясенә кергән һәм социаль ярдәм чараларын алу хокукына ия булган Бөек Ватан сугышында катнашучының тол хатыны. 2010 елның 26 февралендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан торак урын сатып алу өчен түләнә торган акчалата түләү бирү максатыннан ул тиешле исәпкә куелган һәм 2010 елның 16 апрелендә федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак сатып алу өчен субсидияләр алучы гражданнарның республика җыелма исемлегенә кертелгән.

Гражданка М.П. Викторова билгеләп үткәнчә, 2010 елның 31 мартында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларның расланган җыелма исемлеге буенча акча күчерелгән, исемлеккә мөрәҗәгать итүченең әнисе 292 номер белән кертелгән булган. 2010 елның 1 апрелендә гражданка Е.В. Петрова вафат булу сәбәпле җирле үзидарә органнары аны торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар исәбеннән төшереп калдырганнар, алга таба ул торак сатып алу өчен субсидия алучыларның республика җыелма исемлегеннән дә төшереп калдырылган.

Гражданка М.П. Викторова фикеренчә, федераль бюджеттан акча әнисе исән чакта ук күчерелгән булу сәбәпле, ул вафат булганнан соң акча әнисенең варислары тарафыннан алынырга тиеш. Әнисенә торак алу өчен каралган акчаны бүлеп бирү мәсьәләсе буенча ул гомуми юрисдикция судларына дәгъвалар белән мөрәҗәгать иткән, әмма аның таләпләре суд инстанцияләре тарафыннан канәгатьләндерелмичә калдырылган. Мөрәҗәгать итүче санаганча, судларның баш тартуы шул исәптән дәгъва белдерелә торган норма нигезләмәсе белән дә бәйле, ул, аның фикеренчә, гражданнарның аерым категорияләре варислары тарафыннан торак сатып алу өчен субсидия алу хокукын гамәлгә ашыруга каршы килә, чөнки, гражданнар вафат булган очракта, торак урын сатучысына яисә торак урынга таләп итү хокукы булган затка вәкаләтле банк бүлеге счетыннан акча күчергәнчегә кадәр, ягъни федераль бюджеттан региональ бюджетка акча күчергәннән соң, аларны

тиешле исемлекләрдән төшереп калдыру мөмкинлеген бирә. Ул федераль бюджет акчаларын субсидия алучыларның формалаштырылган исемлеге буенча Татарстан Республикасы бюджетына күчергән моменттан субсидиянең файдаланылган дип саналырга тиешлеген күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка М.П. Викторова Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясына (беренче өлеш) туры килми дип тануны сорый, аның нигезендә һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр

исәбеннән торак сатып алу өчен субсидия файдаланылган дип саналу, ә субсидияләр алучылар торак урыннарга мохтаҗлар статусын югалту моментын билгеләүче 14 пунктындагы икенче абзацы әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган Нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацы социаль яклау өлкәсенә һәм торак законнарына кагыла. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы (2 һәм 5 өлешләре) нигезендә Татарстан Республикасы социаль һәм торак өлкәсендә хокукый җайга салуны, федераль законнарга таянып, һәм республика законнары, башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килмәгән очракта гына гамәлгә ашырырга хокуклы.

Россия Федерациясе Торак кодексы торак турындагы законнарның шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының кабул ителгән законнарыннан һәм башка норматив хокукый актларыннан торуын күз алдында тота. Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары әлеге Кодекс, шушы Кодекс нигезендә кабул ителгән башка федераль законнар нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә торак мөнәсәбәтләрен җайга сала торган нормалар булган законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә алалар (5 статьяның 2 һәм 6 өлешләре).

«Ветераннар турында» Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе күрсәтелгән Федераль законның 14, 15, 17—19 һәм 21 статьялары нигезендә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча вәкаләтләрне Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына тапшыра. Әлеге социаль ярдәм чараларын күрсәтү буенча тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелә торган акчалар федераль бюджетта субвенцияләр рәвешендә карала, социаль яклау чараларын күрсәтү формасы Россия Федерациясе субъектының норматив-

хокукый актлары белән билгеләнә («Ветераннар турында» Федераль законның 23.2 статьясындагы 1, 2 һәм 6 пунктлары).

Шулай итеп, «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карарны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә федераль һәм республика законнары нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган, алар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара һәм аларның үтәлешен тикшерә.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), кеше һәм гражданның төп хокуклары һәм ирекләре арасында һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе белән билгеләнгән (7 статья, 40 статьяның 1 һәм 2 өлешләре).

Әлеге конституциячел нормалар һәркемнең лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак торакка хокукны танучы халыкара хокукый нормаларга туры килә (1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомум декларациясенең 25 статьясы, Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында 1966 елның 16 декабрендәге халыкара пактның 11 статьясы).

Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясындагы 2 пункты нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә гражданнарның торакка хокукын гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән бюджет акчаларын һәм законда тыелмаган башка акча чыганакларын гражданнарның торак шартларын яхшырту өчен, шул исәптән торак биналар сатып алу яисә төзү өчен билгеләнгән тәртиптә субсидияләр бирү юлы белән файдаланалар.

Россия Федерациясендә ветераннарны, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзаларын социаль яклауның хокукый гарантияләре «Ветераннар турында» Федераль закон белән беркетелгән.

Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаиләләре әгъзалары өчен билгеләнгән социаль ярдәм чаралары Россия Федерациясенең пенсия законнары нигезендә, һәлак булучының (вафат булучының) хезмәткә яраксыз, аның тәэмин итүендә булучы һәм туендыручысын югалту очрагы буенча пенсия алучы (аны алуга хокукы булган) гаилә әгъзаларына күрсәтелә («Ветераннар турында» Федераль законның 21 статьясындагы 1 пункты).

Күрсәтелә торган социаль ярдәм чаралары арасында әлеге социаль ярдәм күрсәтү чарасын бирү тәртибен билгеләүче «Ветераннар турында» Федераль законның 23.2 статьясы нигезләмәләренә таянып гамәлгә ашырыла торган федераль бюджет акчалары исәбеннән һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү каралган. Күрсәтелгән статья нигезендә субвенцияләр федераль бюджетны үтәү өчен билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары хисапларына күчереләләр (4 пунктча); субвенцияләр бирү өчен акчаларны тоту һәм исәпкә алу тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә (5 пунктча); карала торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру

өчен акчалар максатчан характерда була һәм башка максатларга кулланыла алмый (8 пунктча).

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 15 октябрендәге 614 номерлы карары белән расланган Ветераннарны, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак белән тәэмин итү буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субвенцияләр бирү кагыйдәләре (алга таба шулай ук — Кагыйдәләр) мондый субвенцияләрне бирү тәртибен билгели. Шулай, Кагыйдәләрдә каралганча, Россия Федерациясе Президентының «1941—1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннарын торак белән тәэмин итү турында» 2008 елның 7 маендагы 714 номерлы Указы нигезендә исәпкә баскан Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм инвалидларын, һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзаларын торак белән тәэмин итү өчен субвенцияләр бирү Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан күрсәтелгән Министрлыкка тапшырыла торган гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла (3 пунктның икенче абзацы); торак белән тәэмин итү буенча гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын бирү рәвеше һәм тәртибе Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнә (5 пункт).

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә «Ветераннар турында» Федераль законның 23.2 статьясы нигезләмәләренең югарыда күрсәтелгән Кагыйдәләр белән системалы бәйләнештә, аның ахыргы нәтиҗәсе буларак, федераль закон чыгаручы бары тик ветеран тарафыннан гына торак урын алуны (сатып алуны) күз алдында тоткан, күрсәтелгән федераль бюджет акчаларын Россия Федерациясе субъектлары дәрәҗәсендә ветераннарга адреслы ярдәм күрсәтү өчен

максатчан файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән махсус механизм билгеләнгән (2013 елның 17 гыйнварындагы 3-О номерлы Билгеләмә).

«Ветераннар турында» Федераль законның 23.2 статьясын һәм «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 28.2 статьясын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карарында федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән торак шартларын яхшыртуга хокуклы гражданнарны торак белән тәэмин итү аларга торак сатып алу өчен субсидияләр (алга таба шулай ук — субсидия) бирү юлы белән башкарылуын күз алдында тоткан, субсидияләр бирү буенча чаралар үткәрүгә бәйле функцияләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба — Министрлык) гамәлгә ашыра дип билгеләгән һәм карала торган Нигезләмәне раслаган. Аның белән Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә адреслы ярдәм күрсәтү өчен федераль бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән органнар вәкаләтләре һәм субсидияләр бирү механизмы, шул исәптән субсидия алучыларның җыелма һәм башлангыч исемлекләрен формалаштыру; федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хокукын раслау, субвенцияләр кергәч, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Министрлыкка акчалар күчерү; торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлык өлешендә һәм ташламалы категориягә керү өлешендә субсидия алучылар исемлекләрен актуальләштерү; аңа субсидия бирелү һәм фатир сайлау мөмкинлеге турында субсидия алучыга белдерү; аерым блокланган максатчан шәхси счетын ачу; күчемсез мөлкәткә хокук барлыкка килүне раслаучы шартнамә бирү; акчаларны Министрлыкның шәхси счетыннан субсидия алучылар реестрлары кушымтасы белән вәкаләтле банкның исәп-хисап счетына күчерү җайга салынган.

Нигезләмәнең субсидиянең файдаланылган дип саналу моментын ачыклаучы 14 пунктындагы дәгъва белдерелә торган икенче абзацы, әлеге пунктның башка нормалары белән үзара бәйләнештә гамәлдә була, алар вәкаләтле банкның аның корреспондент счетына һәм субсидияләр алучылар реестрына акчалар кергән вакыттан алып субсидия алучыларның блокланган максатчан шәхси счетларына акчалар күчерү һәм киләчәктә субсидия алучының язма гаризасы нигезендә аларны торак урын сатучысына күчерү бурычын билгели. Бу хәл субсидия алучының торак урынына мохтаҗ статусын югалтуына юридик нигез булып тора.

Әлеге хокукый җайга салу үзенең хокукый мәгънәсе буенча Россия Федерациясе Торак кодексының 56 статьясындагы беренче өлешенең 4 пунктына туры килә, аның нигезендә гражданнар торак урыннарына мохтаҗлар исәбеннән, алар торак урын алу яисә төзү өчен дәүләт хакимияте органыннан яисә җирле үзидарә органыннан билгеләнгән тәртиптә бюджет акчалары алганда төшереләләр. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясындагы бишенче абзацында да эчтәлеге буенча шундый ук нигезләмәләр бар.

Федераль һәм республика законнарының китерелгән нормалары ветераннарга адреслы ярдәм күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары дәрәҗәсендә федераль бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән махсус механизмны ныгыталар.

Нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацында субсидия файдаланылган дип саналу, ә субсидияләр алучылар торак урыннарга мохтаҗлар статусын югалту моментын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысаларында эш иткән һәм хокук кулланучы ягыннан да, шулай ук субсидия алучылар ягыннан да субсидия алучы тарафыннан язма гариза бирү, аерым блокланган

максатчан шәхси счет ачу, күчемсез милеккә хокук барлыкка килүне раслаучы шартнамә бирү кебек таләпләрне билгеләп, аларны максатсыз куллануга юл куймау өлешендә мөмкин булган явыз ниятләрне кисәтүгә юнәлдерелгән максатларны күз алдында тоткан. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мондый тәртипне билгеләү ветераннарның җәмгыять һәм дәүләт алдындагы казанышларын исәпкә алып, аларның социаль ярдәм чараларын алуга хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган өстәмә шартлар тудыра, бу, гомумән алганда, конституциячел әһәмиятле максатка, шул исәптән һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзаларының да хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга җавап бирә.

Югарыда күрсәтелгән максатларга республика җыелма реестры буенча чират нигезендә субсидия алучыларның билгеле бер чиратын формалаштыру өчен җитәрлек күләмдә Татарстан Республикасына акча керү һәм әлеге исемлеккә башка гражданнар белән беррәттән конкрет затны кертү бүлеп бирелә торган акчаларның бер өлешен исемлеккә кертелгән теге яки бу затның милке дип тану өчен бәхәссез нигез булып тормый.

Моннан суд практикасы да килеп чыга, аның нигезендә торак белән тәэмин итү буенча социаль ярдәм чаралары сыйфатында бирелә торган акчалар гражданнар милкенә күчми, ә аларны сату-алу шартнамәсе буенча сатучы счетына күчергәнчегә кадәр дәүләтнеке була һәм мирас милке составына кертелми, ә социаль түләүгә хокук варисларга күчә алмый, чөнки социаль түләү алучы граждан шәхесе белән аерылгысыз бәйле (Россия Федерациясе Югары Судының 2013 елның 27 февралендәге 15-АПГ13-2 номерлы билгеләмәсе).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясенә тулысынча туры килә, ул торак урыны төзү яисә сатып алу өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алу хокукы Бөек Ватан сугышында

катнашучы конкрет гражданның шәхесе белән аерылгысыз бәйле дип ассызыклады (2015 елның 22 декабрендәге 2793-О номерлы билгеләмә).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацы үзенең эчтәлеге һәм максатчан билгеләнеше буенча дәүләт тарафыннан гражданнарның аерым категорияләрен, аерым алганда, һәлак булган (вафат булган) Бөек Ватан сугышы инвалидларының һәм Бөек Ватан сугышында катнашучыларның гаилә әгъзалары тарафыннан торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру чараларын тәэмин итүгә юнәлдерелгән механизмның бер элементы булып тора, аның хокукый табигате карала торган социаль ярдәм чарасын сорап мөрәҗәгать итүче гражданнар һәм мондый гражданнарга субсидияләрне адреслы бүлүне тәэмин итүдә вәкаләтле органнарга йөкләнгән функцияләрне һәм бурычларны үтәгәндә алар тарафыннан мөмкин булган явыз ният белән файдалануларны булдырмау зарурлыгына бәйле, гражданнарның күрсәтелгән субсидияне алу хокукы асылына каршы төшми, аның мәгънәсе югалуга китерми, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән гражданка М.П. Викторованың да конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган итеп карала алмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясына (беренче өлеш) туры килә.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2006 елның 7 июнендәге 275 номерлы карары белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәнең 14 пунктындагы икенче абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 98-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**